Казан федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара багланышлар  институты
Г.Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе

Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр
фәнни белем бирү үзәге

# ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕЛЕМЕН ТИКШЕРҮ ТЕСТЛАРЫ ӨЧЕН КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (СПЕЦИФИКАЦИЯ)

## ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘ

**КАЗАН**
**2024**

**1**. Контроль бәяләү материаллары татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләрнең телне үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү өчен әзерләнде. Тәкъдим ителә торган үрнәкләр туган телне яхшы белүчеләргә, ягъни татарча язма һәм телдән сөйләмне югары дәрәҗәдә үзләштерүчеләргә юнәлдерелгән. Материаллар әзерлек сыйфатын объектив бәяләүне күздә тота.

## 2. Эчтәлекне сайлау һәм үрнәк материалларны төзү алымнары

Татар телен туган тел буларак югары дәрәҗәдә үзләштерүнең максаты – көндәлек һәм матур әдәбият телен аңлап куллана белү, куллана торган татар сөйләме үрнәкләрен язма һәм сөйләмә телдә актив һәм дөрес куллану, татар сөйләме калыпларын, халык авыз иҗаты ядкярләренең семантик һәм функциональ нечкәлекләрен аңлап куллану, орфографик һәм орфоэпик закончалыкларны, грамматик кагыйдәләрне белү, туган телдә аралашу мөмкинлекләрен киңәйтү.

Телне югары дәрәҗәдә өйрәнүчеләрнең коммуникатив эшчәнлеген һәм тел закончалыкларын үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү өчен, тест вакытында төрле типтагы биремнәр файдаланыла.

Тест үтәргә дәгъва кылучыларның тәкъдим ителгән биремнәрне башкарып чыгуы аларның туган тел буларак татар телен югары дәрәҗәдә үзләштерүләрен ачыклый.

## 3.Тестның төзелеше һәм эчтәлеге

Тест биремнәре дүрт төрле сөйләм эшчәнлеге: тыңлап аңлау, укып аңлау, язма сөйләм, телдән сөйләм биремнәре кысасында бирелә. Бу бүлекләрдә төрле төзелештәге биремнәр урын ала.

Тест үтүчеләргә бирелгән 4 җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, бирелгән 4 җавапның берсен яки берничәсен сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр, тәңгәллекләр урнаштыруны таләп иткән биремнәр, кыска җавап язуны яки киңәйтелгән җавап язуны таләп иткән ачык типтагы биремнәр, тәкүдим ителгән темаалрның берсен сайлап алып, телнең

сүз-сурәтләү мөмкинлекләрен дөрес һәм киң кулланып, инша язу һәм, рәсемнәрне тасвирлап, киңәйтелгән җавапны телдән сөйләп бирүне таләп иткән ачык типтагы биремнәр тәкъдим ителә.

*Төзелеше ягыннан* тест биремнәре 3 төрле була.

1 нче төр - җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр. Бу өлештә тәкъдим ителгән биремнәр тыңланган һәм укылган текстларның төп эчтәлеген аңлау һәм алардан кирәкле мәгълүматны табу, лексик-грамматик, стилистик күнекмәләрен тикшерүгә юнәлдерелгән.

2 нче төр биремнәре – кыска җавапны язу, тәңгәллекләр урнаштыру биремнәре. Контексттан аңлашылган сүзне яки сүзтезмәне, яисә тәкъдим ителгән берәмлекләрне синонимнары, антонимнары, фразеологик, мәкаль-әйтемнәрне яки телнең башка лексик-грамматик, фонетик күренешләрен табып язу биремнәре дә икенче төрне тәшкил итә.

3 нче төр биремнәр тест үтүченең телдән яки язма сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота. Мондый төр биремнәргә тәкъдим ителгән мәкальгә нигезләнеп, кечкенә күләмле инша язу, рәсемне тасвирлап сөйләү кебекләр карый.

Тестта биремнәрнең чагылышы 1 нче таблицада бирелә.

*1 нче таблица*

**Биремнәрнең тестта чагылышы**

| Тест бүлекләре | Биремнәрнең саны | Иң югары (максималь) балл | Биремнәрнең төрләре |
|---|---|---|---|
| Тыңлап аңлау (диалог) | 4 | 4 | Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | биремнәр |
| Тыңлап аңлау (монолог) | 2 | 6 | Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр |
| | 2 | 6 | Кыска җавап бирү биремнәре |
| Укып аңлау (1нче текст) | 5 | 5 | Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр |
| | 2 | 6 | Кыска җавап бирү биремнәре |
| Укып аңлау (2нче текст) | 5 | 13 | Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр |
| | 3 | 12 | Тәңгәллекләр булдыру биремнәре |
| Язма сөйләм күнекмәләрен тикшерү | 1 | 24 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән бирем |
| Телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерү | 1 | 24 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән бирем |
| Барлыгы | 25 | 100 | |

## 4. Тест биремнәрен эчтәлегенә һәм эш төрләренә нигезләнеп бүлү

Тестта татар телен әзерлек дәрәҗәсендә үзләштергән тел өйрәнүчеләрнең түбәндәге коммуникатив компетенцияләргә ия булуы тикшерелә:

- тыңланган текстның төп эчтәлеген һәм сорала торган мәгълүматны аңлый белүе;
- укылган текстның төп эчтәлеген һәм сорала торган мәгълүматны аңлый белүе;
- тел берәмлекләрен коммуникатив яктан мөһим булган контекстта куллану күнекмәләренә (лексик-грамматик күнекмәләргә) ия булуы;
- киң кулланылыштагы халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныш булуы;
- үз фикерен язма сөйләмдә чагылдыра белүе;
- телдән сөйләм күнекмәләренә ия булуы.

## 5. Биремнәрне катлаулылык дәрәҗәсеннән чыгып бүлү

Тестның катлаулылык дәрәҗәсе тел материалының һәм тикшерелә торган күнекмәләрнең катлаулылыгына, шулай ук биремнең төренә карап билгеләнә.

Тестта 3 төрле катлаулылыктагы биремнәр тәкъдим ителә.

3 *нче таблица*

**Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше**

| Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремнәрнең саны | Иң югары балл | Иң югары баллдан чыгып, биремнәрнең әлеге өлеше өчен куелган балл, процентларда |
|---|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә (А) | 14 | 27 | 27% |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә (Б) | 9 | 25 | 25% |
| Өченче дәрәҗә (С) | 2 | 48 | 48% |
| Барлыгы | 25 | 100 | 100 % |

**6. Биремнәрнең үзенчәлекләре**

1 нче бүлектә (тыңлап аңлау биремнәре) тест үтүчеләр диолог һәм монолог тыңлыйлар. Аларда көндәлек тормыш вакыйгасына бәйле сөйләм гыйбарәләре, тасвирлаулар, татар этикетына караган сөйләм калыплары кулланыла. Диалогның озынлыгы 40-50 секунд, монологныкы – 120 секунд, якынча 190-230 сүзне үз эченә ала.

2 нче бүлектә (уку өчен тәкъдим ителгән биремнәр**)** әдәби әсәрләрдән, вакытлы матбугат язмаларыннан алынган тасвирлау характерындагы текстлар, сөйләмдә кулланылышта булган мәкаль һәм әйтемнәр, һөнәри һәм диалекталь сүзләр файдаланыла. Уку өчен тәкъдим ителгән текстларның күләме 250-300 сүз тәшкил итә.

3 нче бүлектә (язма сөйләмне тикшерү биремнәре) сайлап алу биреме китерелә. Язма сөйләмне тикшерү өчен, бирелгән 2 мәкальнең берсен сайлап алып, аңа карата үз фикереңне белдереп, 300 сүздән ким булмаган инша язу эше тәкъдим ителә.

4 нче бүлектәге бирем (телдән сөйләмне тикшерү биремнәре) тәкъдим ителгән рәсемнәрнең берсен сайлап алып тасвирлауны күз уңында тота. Тест үтүче тормышчан ситуацияне тасвирлаган рәсем турында сөйләргә, сөйләмен бәйләнешле текст рәвешендә оештырырга тиеш. Телдән сөйләм тексты 20-25 җөмләдән торырга тиеш.

**7. Тест үткәрү вакыты**

Тест үткәрү өчен, 165 (150 + 15) минут вакыт бирелә.

## 8. Аерым биремнәрне һәм эшне тулаем бәяләү системасы

**1 нче бүлектәге** 1-4 нче биремнәр аудиоязмадан диалог текстын тыңлаганнан соң башкарыла. Тест үтүчеләр дүрт тәкъдим ителгән җаваптан берсе дөрес булган сайлап алу биремнәрен үтиләр. Һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.

5-8нче биремнәр аудиоязмадан монолог тыңлаганнан соң башкарыла. 5-6 биремнәре - сайлап алу текстлары. Анда бирелгән гыйбарәнең текстның эчтәлегенә туры килүен, (дөрес), эчтәлеккә туры килмәвен (дөрес түгел) яки текстта бу хакта әйтелмәвен (текстта әйтелмәгән) ачыкларга кирәк. Һәр дөрес җавап 3 балл белән бәяләнә.

7-8 нче биремнәрдә текстның эчтәлегенә бәйле тәкъдим ителгән җөмләдә төшеп калган сүзне язу сорала. Бу – кыска җавап язу биремнәре. Һәр дөрес җавап 3 балл белән бәяләнә.

Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен, иң югары **16** балл җыярга мөмкин. Биремнәр программа ярдәмендә тикшерелә.

**2 нче бүлектәге** биремнәр укылган текстлар белән эшне күз уңында тота. 9-13нче биремнәр - дүрт тәкъдим ителгән җаваптан берсе дөрес булган сайлап алу биремнәре. Һәр дөрес җавап 3 балл белән бәяләнә;

14-15нче биремнәр - текстның эчтәлегенә бәйле тәкъдим ителгән җөмләдә төшеп калган сүзне язу биремнәре (кыска җавап язу биремнәре). Һәр дөрес җавап 3 балл белән бәяләнә;

16-18 нче биремнәр - текстта төшеп калган сүзләрнең дөрес грамматик формасын сайлау биремнәре (өч тәкъдим ителгән җаваптан берсе дөрес булган сайлап алу биремнәре). Һәр дөрес җавап 3 балл белән бәяләнә;

19-20 нче биремнәр - дүрт тәкъдим ителгән җаваптан икесе дөрес булган сайлап алу биремнәре. Һәр дөрес җавап 3 балл белән бәяләнә;

21 нче бирем - тәңгәлләштерү тибына карый. Бу биремгә 4 балл куела. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

22-23нче биремнәр – шулай ук тәңгәллекләр урнаштыруга карый, әмма анда ике артык җавап варианты тәкъдим ителә. Һәр дөрес җавап 4 балл белән бәяләнә. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен иң югары **36 балл** җыеп була. Биремнәр программа ярдәмендә тикшерелә.

**3 нче бүлектәге** бирем, тәкъдим ителгән темаларның берсен сайлап алып, бәйләнешле текст төзеп язуны таләп итә. Тест үтүче 300 сүздән ким булмаган текст язарга тиеш. Язма эш тесторлар тарафыннан тикшерелә.

**Язманы бәяләү критерийлары**:

| № | Иншаны бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Эчтәлекне дәлилләүче ике мисал бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Эчтәлекне дәлилләүче 1 мисал бирелгән. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Эчтәлекне дәлилләүче мисаллар юк. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылган, ләкин эчтәлекне аңлауда хаталар бар. Яки дәлилләр эчтәлеккә туры килми. | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган, мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана, абзацларга бүленештә хаталар юк,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар. | 3 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана, логик хаталар юк,<br>**ләкин** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар.<br>**һәм**<br>абзацларга бүленештә 1 хата бар | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 2 яки артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк | 4 |
| | 1-2 хата җибәрелгән | 3 |
| | 3-4 хата бар | 2 |
| | 5 хата бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5тән күбрәк | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк | 4 |
| | 1 хатасы бар. | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | 2 хатасы бар. | 2 |
| | 3 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарның саны 3 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 4 |
| | 1 хатасы бар. | 3 |
| | 2 хатасы бар. | 2 |
| | 3 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарның саны 3 тән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы хаталары юк. | 2 |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1-2 хатасы бар. | 1 |
| | Сөйләмгә кагылышлы хаталар саны 3 яки күбрәк | 0 |
| | Текстта сүзләр саны 300 дән ким түгел | 2 |
| | Текстта сүзләр саны 250 - 299 күләмендә | 1 |
| | Текстта сүзләр саны 249 дfн кимрәк | 0 |
| **Язма эш өчен иң югары балл** | | **24** |

**4 нче бүлектәге** биремдә телдән сөйләм күнекмәләре тикшерелә. Телдән сөйләнгән текстның коммуникатив бурычны үтәү дәрәҗәсе, җөмләләр саны, сөйләмне оештыру дәрәҗәсе, грамматик элементларның дөрес файдаланылуы, туган телнең лексик, орфоэпик нормалары, басым, интонация үзенчәлекләре исәпкә алына. Укучыдан 8-10 җөмләдән торган текст төзү сорала.

| № | Иншаны бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | **Коммуникатив бурычны үтәү** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Рәсем дөрес тасвирланган. Лексик берәмлекләр һәм стилистик чаралар дөрес сайланган, эчтәлек тулысынча ачылган. Төрле лексик берәмлекләр файдаланылган. Сөйләүче үз фикерен җиткергән. | 4 |
| | Рәсем дөрес тасвирланган. Лексик берәмлекләр һәм стилистик чаралар дөрес сайланган, эчтәлек тулысынча ачылган. Бертөрле лексик берәмлекләр файдаланылган. Сөйләүче үз фикерен җиткергән. | 3 |
| | Рәсем тасвирланган. Лексик берәмлекләр һәм стилистик чаралар дөрес сайланган, эчтәлек тулысынча ачылган. Сөйләүче үз фикерен җиткермәгән | 2 |
| | Рәсем тасвирланган. Бертөрле лексик берәмлекләр һәм стилистик чаралар сайланган, эчтәлек өлешчә ачылган. Сөйләүче үз фикерен җиткермәгән | 1 |
| | Рәсем тасвирланмаган. Тел һәм стилистик чаралар гади һәм бертөрле. Сөйләүче үз фикерен җиткермәгән. | 0 |
| ***II*** | **Сөйләмне оештыру** | |
| | **Сөйләмнең мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, эзлеклелеге** | |
| | Сөйләм мәгънәви бөтенлеге, бәйләнешлелеге һәм эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, сөйләмдә эзлеклелек бозылмаган;<br>– төрле сурәтләү чаралары кулланылган. | 4 |
| | Сөйләм мәгънәви бөтенлеге, бәйләнешлелеге һәм эзлеклелеге белән характерлана, **ләкин** 1 логик хатасы бар. | 3 |
| | Сөйләм мәгънәви бөтенлеге, бәйләнешлелеге һәм эзлеклелеге белән характерлана, **ләкин** бертөрле сөйләм калыплары гына кулланыла. | 2 |
| | Сөйләм мәгънәви бөтенлеге, бәйләнешлелеге һәм өлешчә | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | эзлеклелеге белән характерлана, **ләкин** 1 логик хатасы бар. | |
| | Сөйләмне үстерүгә омтылыш бар, **ләкин** логик хаталарның саны 2 яки артык. | 0 |
| ***III*** | ***Сөйләмне тел ягыннан оештыру*** | |
| | **Орфоэпик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфоэпик хаталары юк | 4 |
| | 1-2 хата җибәрелгән | 3 |
| | 3-4 хата бар | 2 |
| | 5 хата бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5тән күбрәк | 0 |
| | **Сүз басымының дөрес куелышы** | |
| | Хаталары юк | 4 |
| | 1 хатасы бар. | 3 |
| | 2 хатасы бар. | 2 |
| | 3 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарның саны 3 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Лексик һәм грамматик хаталары юк. | 4 |
| | 1 хатасы бар. | 3 |
| | 2 хатасы бар. | 2 |
| | 3 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарның саны 3 тән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм төгәл, төрле җөмлә калыплары файдаланыла. | 2 |
| | Сөйләм төгәл, бертөрле җөмлә калыплары файдаланыла. | 1 |
| | Сөйләмгә кагылышлы хаталар бар. | 0 |
| | Текстта 20-25 җөмлә бар. | 2 |
| | Текстта җөмләләр саны 17-19. | 1 |
| | Текстта 16 яки кимрәк җөмлә бар. | 0 |

| **Язма эш өчен иң югары балл** | **24** |
|---|---|

Биремнәрне үтәү барышында җыелган **иң югары балл** – 24. Язма эш тесторлар тарафыннан бәяләнә.

## 9. Тест үткәрүгә куелган таләпләр

Тестны үтү өчен 165 минут вакыт кирәк. 150 минут – 1-3нче бүлекләрен үтәү өчен тәкъдим ителә. Биремнәрне эзлекле рәвештә башкару сорала. Эшләнми калган биремгә кире кайту программада каралмаган.

4нче бүлек биреме өчен һәр тест үтүчегә 15 минут вакыт бирелә.

Тест махсус программа аша компьютер аркылы да, мөмкинлек һәм шартлар чикле булган очракта, кәгазьгә чыгартылган биремнәр рәвешендә дә башкарыла ала.

Телдән сөйләмне тикшерү өлеше камера аша сөйләнелә, әңгәмә аудиоматериал буларак яздырылып бара.

Тест үтүче вакытка сыешмаган очракта, аның җаваплары сакланмый.

## 10. Тест үздыру өчен үрнәк материалларның гомумиләштерелгән планы.

*Кушымта*

**Тест үздыру өчен үрнәк материалларның гомумиләштерелгән планы**

| **Биремнәренң номеры** | **Тикшерелә торган эшчәнлек төре** | **Катлаулык дәрәҗәсе** | **Биремнең тибы** | **Тәкъдим ителә торган вакыт** |
|---|---|---|---|---|
| **1** | **Диалогны тыңлау һәм сайлап алу биремен** | **1** | **А** | **10** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **башкару** | | | **мин.** |
| **2** | **Диалогны тыңлау һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **3** | **Диалогны тыңлау һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **4** | **Диалогны тыңлау һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **5** | **Монологны тыңлау һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | **15 мин** |
| **6** | **монологны тыңлау һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **7** | **Монологны тыңлау һәм кыска җавап язу биремен башкару** | **2** | **B** | |
| **8** | **Монологны тыңлау һәм кыска җавап язу биремен башкару** | **2** | **B** | |
| **9** | **1нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | **15 мин** |
| **10** | **1нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **11** | **1нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **12** | **1нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **13** | **1нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **14** | **1нче текстны уку һәм кыска җавап язу биремен башкару** | **2** | **B** | |
| **15** | **1нче текстны уку һәм кыска җавап язу биремен башкару** | **2** | **B** | |
| **16** | **2нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | **15 мин** |
| **17** | **2нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |
| **18** | **2нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **1** | **A** | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **19** | **2нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **2** | **B** | |
| **20** | **2нче текстны уку һәм сайлап алу биремен башкару** | **2** | **B** | |
| **21** | **Мәкальләрне уку һәм тәңгәллекләр башкару** | **2** | **B** | **10 мин** |
| **22** | **Фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре арасында тәңгәллекләр башкару** | **2** | **B** | **10 мин** |
| **23** | **Сүзләр һәм хәрефләр арасында тәңгәллекләр башкару** | **2** | **B** | **15 мин** |
| **24** | **Мәкаль нигезендә, дәлилләр китереп, инша язу** | **3** | **C** | **60 мин** |
| **25** | **Рәсемне тасвирлап, телдән сөйләм тексты оештыру** | **3** | **C** | **15 мин** |